СОВЕТ
МЕНЗЕЛИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНЗӘЛӘ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

16 октябрь 2018 ел г.Мензелинск № 5

**«2019 елга Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районының юл хәрәкәте иминлеген күтәрү “ максатчан Программасы турында”**

Минзәлә муниципаль район башкарма комитеты җитәкчесе вазифаларын башкаручы Д.А.Чухланцевның докладын һәм 03.10.2013 елда кабул ителгән Россия Федерациясе Хөкүмәтенең №864 Карары белән расланган 2013-2020 елларга юл хәрәкәте иминлеген күтәрү Федераль максатчан Программасының төп күрсәткечләрен тыңлаганнан һәм тикшергәннән соң,

**Минзәлә муниципаль район Советы карар чыгарды:**

1. “2019 елга ТР Минзәлә муниципаль районының юл хәрәкәте иминлеген күтәрү” максатчан программасын расларга (бирелгән).
2. “2019 елга ТР Минзәлә муниципаль районының юл хәрәкәте иминлеген күтәрү” Максатчан программасының үтәлешен тәэмин итәргә, районда юл хәрәкәте иминлеген күтәрү өчен шартлар тудыру буенча чаралар күрергә.
3. Ел саен ел ахырында “2019 елга ТР Минзәлә муниципаль районының юл хәрәкәте иминлеген күтәрү” максатчан программасының үтәлеше турында мәгълүмат тыңларга.
4. Гамәлдәге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Советның төзелеш, газификация, электр белән тәэмин итү, элемтә, транспорт һәм юллар буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Минзәлә муниципаль район
Башлыгы, район Советы рәисе А.Ф. Салахов

Раслыйм
Минзәлә муниципаль районының
район Советы рәисе
______________ А.Ф. Салахов

# "2019 ЕЛГА МИНЗӘЛӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНДА ЮЛ ХӘРӘКӘТЕ ИМИНЛЕГЕН КҮТӘРҮ” МАКСАТЧАН ПРОГРАММАСЫ ПАСПОРТЫ

| | |
|---|---|
| Программаның исеме | -“2019 елга ТР, Минзәлә муниципль районында юл хәрәкәте иминлеген күтәрү” максатчан Программасы |
| Карарның кабул итү датасы | -Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 03.10.2013 елда кабул ителгән №864 Юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итү буенча Хөкүмәт комиссиясе федераль максатчан программасын раслау турындагы 02.11.2006 елда кабул ителгән №3 Карары нигезендә эшкәртелгән; |
| Заказчы-координатор | -Минзәлә муниципаль район башкарма комитеты; |
| Программа заказчылары | -Минзәлә муниципаль район Советы |
| Программаны төп эшкәртүчеләр | - Минзәлә муниципаль район башкарма комитеты;<br>-Эчке эшләр министрлыгының Минзәлә муниципаль районы буенча бүлеге<br>-ТР Минзәлә эчке эшләр бүлегенең ЮХИДИ бүлекчәсе;<br>-Гадәттән тыш хәлләр министрлыгының ТР Минзәлә муниципаль район идарәсе;<br>-Минзәлә муниципаль район Башкарма комитетының мәгариф бүлеге;<br>-“Минзәлә район үзәк хастаханәсе” сәламәтлек саклау |

| | |
|---|---|
| | муниципаль учреждениесе |
| Программаның максатлары һәм бурычлары | 2020 елга юл-транспорт фаҗигаләрендә үлем очракларын 3 кешегә киметү (28,82 процентка, ә 2019 елга 2012 ел белән чагыштыргандагы күрсәткечләрне арттырмыйча, 2,64%ка);<br>бурычлар түбәндәгечә:<br>- юл хәрәкәте өлкәсендә хокук бозуларга негатив мөнәсәбәт формалаштыру максатыннан пропаганда системасын булдыру; балаларда юлларда үз-үзләрен куркынычсыз тоту күнекмәләрен формалаштыру;<br>- автотранспорт йөртү культурасын арттыру;<br>- юл-транспорт һәлакәтләрендә зыян күрүчеләргә ярдәм күрсәтүнең заманча системасын үстерү;<br>- транспорт чаралары белән идарә итүгә хокук алуга әзерлек һәм шушы әзерлекне тормышка ашыручы автомәктәпләргә таләпләрне катгыйландыру; |
| Мөһим максатчан күрсәткечләр һәм индикаторлар | -Программаның мөһим күрсәткечләре түбәндәгеләр:<br>юл-транспорт фаҗигаләрендә һәлак булучыларның санын киметү;<br>-Программаның мөһим индикаторлары түбәндәгеләр:<br>-транспортта йөрү куркынычын киметү (10 мең транспорт чарасына юл-транспорт фаҗигаләрендә һәлак булучы затлар саны);<br>-социаль куркынычны киметү (100 мең халыкка юл-транспорт фаҗигаләрендә һәлак булучы затлар саны);<br>-нәтиҗәләр авырлыгын киметү;<br>-юл-транспорт фаҗигаләре концентрациясе урыннары санын кыскарту;<br>-машина йөртү стажы 3 елдан артмаган машина |

| | |
|---|---|
| | йөртүчеләр катнашындгы юл-транспорт һәлакәтләре санын кыскарту;<br>-үз саксызлыгы нәтиҗәсендә юл-транспорт фаҗигаләре нәтиҗәсендә зыян күргән балалар санын киметү. |
| Программаны тормышка ашыруның сроклары һәм этаплары | -Программа 2019 елга исәпләнгән; |
| Программаны Финанслау күләме һәм чыганаклары | -Программаны финанслауның гомуми күләме - 81 081мең сум:<br>-ТР бюджеты чаралары хисабыннан –41 600 сең сум;<br>-җирле бюджет чаралары хисабыннан – 36 090 мең сум;<br>-бюджеттан тыш чыганаклар хисабыннан – 6 500 мең сум; |
| Программаны тормышка ашыруның көтелгән соңгы нәтиҗәләре һәм нәтиҗәлелек күрсәткечләре эффективности | -2019 елга юл-транспорт фаҗигаләре нәтиҗәсендә һәлак булучы затларның санын 2012 елдагы шундый күрсәткеч белән чагыштырганда, социаль-икътисадый торыш 2,64 процентка кыскарту; |

I.

## II. Проблеманың характеристикасы

III. Куркынычсыз юл хәрәкәтендә юл-транспорт инфраструктурасының җәмгыять һәм дәүләт ихтыяҗларына туры килмәве, юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итү системасының тиешенчә нәтиҗәле булмавы һәм юл хәрәкәтендә катнашучыларның дисциплинасы чиктән тыш түбән булуы сәбәпле, автомобиль транспорты белән бәйле аварияләр проблемасы (алга таба – аварияләр проблемасы) соңгы дистә елда кискен төс алды.

Юл хәрәкәте иминлеге Минзәлә районының мөһим социаль-икътисадый һәм демографик мәсьәләләренең берсе булып тора. Автомобиль транспортындагы аварияләр проблемасы гомумән алганда җәмгыятькә, шулай ук аерым гражданнарга чамадан тыш матди һәм мораль зыян китерә.

Юл-транспорт травматизмы хезмәткә яраклы яшьтәгеләрнең производство өлкәсеннән төшеп калуына китерә. Балалар һәлак була яисә инвалид булып кала.

Юл-транспорт иминлеген тәэмин итү шәхси иминлекне, демографик, социаль һәм икътисадый проблемаларны хәл итү, тормыш сыйфатын күтәрү һәм региональ үсешкә ярдәм итү буенча мәсьәләләрнең бер өлеше булып тора

Россия Федерациясе Президентының 2007 елның 9 октябрендә расланган №1351 Карары белән, 2025 елга кадәр Россия Федерациясе демографик сәясәте Концепциясе нигезендә, халыкның үлем очракларын киметү, иң беренче чиратта тышкы сәбәпләрдән хезмәткә яраклы ир-атларның, шул исәптән, юл-транспорт фаҗигаләре нәтиҗәсендә үлем очракларының югары булуын киметү демографик сәясәтнең иң мөһим юнәлешләренең берсе.

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2011 елның 10 мартында расланган №367-р боерыгы белән, 2025 елга кадәр чорга Россия Федерациясенең 2011-2020 елларга демографик сәясәт Концепциясен тормышка ашыру буенча чаралар планы нигезендә, “2019 елга татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районында юл хәрәкәте иминлеген күтәрү” максатчан программасы (алга таба – Программа) 2020 нче елга кадәр демографик сәясәтнең максатларына ирешү инструментларының берсе булып тора.

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2001 елның 5 декабрендә расланган №848 карары белән расланган “(2010-2020 елларга) Россиядә транспорт системасын

үстерү” Федераль максатчан программасына норматив таләпләргә туры килгән максатчан индикаторлары федераль әһәмияткә ия булган гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын озынайтуга юнәлтелгән эшчәнлекне чагылдыручы “Автомобиль юллары” подпрограммасы керә. “Автомобиль юллары” подпрограммасын тормышка ашыруның көтелгән нәтиҗәләре федераль әһәмияткә ия булган автомобиль юлларының үткәрү мөмкинлеген чикләүне киметү (халыкара транспорт коридорлары составында түләүле автомобиль һәм тизйөрешле юлларны да кертеп), юллар төзү һәм реконструкцияләү күздә тотыла. Федераль бюджеттан финанслау шартларында региональ һәм муниципальара әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү һәм реконструкцияләү планлаштырыла.

2014 елдан Минзәлә муниципаль районында җирле әһәмияткә ия булган муниципаль юлларны норматив тәңгәллеккә китерүгә юнәлтелгән юл фондлары формалаштырылды. 2019 елга 17 700 мең сум күләмендә финанслау каралган.

2020 елга кадәр чорга Россия Федерациясенең озак сроклы социаль-икътисадый үсеш Концепциясендә транспортның үсеш сферасында дәүләт сәясәтенең тәкъдим ителгән максатларының берсе булып комплекслы иминлекне һәм транспорт системасының ныклыгын күтәрүне кертеп, икътисадның көндәшлеккә сәләтлелеген һәм халык тормышының сыйфатын үстерү өчен шартлар тудыру тора.

Шул рәвешле, юл хәрәкәтендә катнашучыларның тормышын һәм сәламәтлеген саклау (юллардагы дисциплинаны, юл инфраструктурасы сыйфатын күтәрү, юл хәрәкәтен оештыру, зыян күрүчеләргә медицина ярдәмен оператив һәм сыйфатлы күрсәтү хисабына) һәм, нәтиҗә буларак, юл-транспорт фаҗигаләреннән демографик һәм социаль-икътисадый зыянны һәм нәтиҗәләрен кыскарту Россия Федерациясенең социаль-икътисадый үсешенең өстенлекле бурычлары озак сроклы һәм уртача сроклы перспективада килешенгән һәм халык санының кимү темпларын, аның саны арту өчен шартлар тудыруныtәэмин итүгә юнәлтелгән.

Район территориясендә административ материалларны башкару өчен мөрәҗәгать итү процедураларын тормышка ашыруны тәэмин итә торган хокук бозуларны автоматлашкан фиксацияләү системасы булдырылган һәм функцияләшкән.

Юл-транспорт аварияләре белән бәйле проблемаларны нәтиҗәле хәл итү, аның күрсәткечләрен алга таба үсеш алган илләр дәрәҗәсендә киметү өчен юл хәрәкәте иминлеген күтәрү һәм аларны финанс ресурслары белән тәэмин итү буенча чараларны системалы тормышка ашыру өчен, моңа бәйле рәвештә юл хәрәкәте иминлеген түбәндәге максатларда күтәрү буенча комплекслы чараларны тормышка ашыруның институциональ тәэмин ителешен алга таба үстерүне таләп итә:

җәмгыять тарафыннан юл хәрәкәте куркынычын аңлау һәм юлларда куркынычсыз хәрәкәтне тәэмин итү буенча дәүләт мөмкинлекләрен һәм чаралары балансын саклау;

юл хәрәкәтендә катнашучыларның хокук бозып һәм үз-үзләрен агрессив тотуына карата Россия Федерациясе законнарын куллану мөмкинлеген һәм башка тәэсир итү чараларын киңәйтү;

транспорт чаралары һәм җәяүлеләр хәрәкәтен оештыру өлкәсендә оештыру-хокукый һәм оештыру-техник функцияләрне тормышка ашыру мәсьәләләрен җайга салу;

куркынысыз юл хәрәкәте өлкәсендә юл-транспорт инфраструктурасын норматив таләпләр белән тәңгәл китерү;

юл хәрәкәте иминлеген һәм нәтиҗәгә ирешү өчен аларның икътисадый кызыксынуын тәэмин итү буенча финанслауда булышу чараларын тормышка ашыру һәм Россия Федерациясе субъектларын җәлеп итү механизмнарын системалы эшкәртү;

Булган проблемаларны хәл итүнең нәтиҗәле дәвамы юл-транспорт иминлеген тәэмин итү өлкәсендә Программаны кабул итү һәм алга таба тормышка ашыру аша куллануның вакытын озайту шартларында максатчан программа ысулын нигез итеп алганда гына мөмкин, чөнки бу түбәндәге мөмкинлекләр бирә:

аварияләргә китерүче сәбәпләргә нигезле һәм системалы тәэсир итүче юл хәрәкәте иминлеген күтәрү буенча өстенлекле чаралар системасын формалаштырырга:

федераль, региональ һәм җирле дәрәҗәдә, шулай ук ведомствоара һәм дәрәҗәара өлкәдә үзара бәйләнеш һәм башкарма хакимиятнең федераль органнары координациясе, Россия Федерациясе субъектларының башкарма хакимияте

органнары һәм җирле үзидарә органнарының юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итү өлкәсендә идарә итүнең нәтиҗәлелеген күтәрү;

юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итү өлкәсендә өстенлекле максатларга һәм бурычларга тәңгәл килгән чараларны тормышка ашыруга дәүләт ресурсларын тупларга;

нәтиҗәгә ориентлашкан бюджетны планлаштыру принципларын кулланырга.

## IV. Программаның максаты һәм бурычлары, аны тормышка ашыруның сроклары һәм этаплары, шулай ук аның үтәлеше барышын чагылдыручы максатчан индикаторлар һәм күрсәткечләр

Юл-транспорт фаҗигаләре нәтиҗәсендә үлем очракларын, шул исәптән, балалар үлемен 2012 ел белән чагыштырганда 2020 елга 3 кешегә (28,82 процент) кимету Программаның максаты булып тора.

Юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итү буенча түбәндәге бер-берсен тулыландыра торган өстенлекле бурычлар билгеләүгә системалы якын килүне куллану билгеләнгән максатка ирешүне күздә тота:

юл хәрәкәте өлкәсендәге хокук бозуларга негатив мөнәсәбәт формалаштыру максатыннан, халыкка пропаганда аша тәэсир итү системасын булдыру;

балаларда юлларда иминлек саклау күнекмәләрен формалаштыру;

автомобиль йөртү культурасын күтәрү;

юл-транспорт һәлакәтләрендә зыян күрүчеләргә ярдәм күрсәтүнең заманча системасын үстерү;

транспорт чаралары белән идарә итүгә хокук алу өчен машина йөртүчеләрне әзерләү таләпләрен һәм мондый әзерлекне башкаручы автомәктәпләргә таләпләрне күтәрү.

Программаның бурычлары Россиядә юл-транспорт травматизмын киметү буенча эшчәнлек юнәлешләрен һәм аларны детальләп аңлатучы чараларның координацияләнгән системасын булдырырга, шулай ук түбәндәгеләрне тәэмин итәргә мөмкинлек тудыралар:

юл хәрәкәтендә катнашучыларга грамоталы, җаваплы һәм имин торыш өчен шартлар;

ресурслар белән функциональ идарә итү принцибыннан эшчәнлекнең конкрет юнәлешләрен проектлы финанслауга күчү;

Программа чараларын тормышка ашыруга Россия Федерациясе субъектларын, муниципаль берәмлекләрне һәм дәүләтнеке булмаган оешмаларны актив җәлеп итәргә;

дәүләт, муниципаль һәм шәхси секторда гражданлык җәмгыятен дә җәлеп итеп, барлык кызыксынган яклар катнашында хезмәттәшлек һәм партнерлык.

Программаның тормышка ашырылган еллары буенча максатларына ирешүгә бәя түбәндәге максатчан индикаторлар һәм Программа күрсәткечләрен кулланып башкарыла:

юл-транспорт фаҗигаләрендә һәлак булучылар саны;

юл-транспорт фаҗигаләрендә һәлак булучы балалар саны;

социаль куркыныч (100 мең кешегә юл-транспорт фаҗигаләрендә һәлак булучылар саны);

транспорт куркынычы (10 мең транспорт чарасына юл-транспорт фаҗигаләрендә һәлак булучылар саны);

Программаның тормышка ашырырылган еллары буенча максатчан индикаторлар һәм күрсәткечләр кушымта №1 дә китерелгән.

2019 елда Программаны тормышка ашыру нәтиҗәләрен анализларга һәм күрсәткечләрне, индикаторларны һәм Программа чаралары исемлеген корректировкалау буенча тәкъдимнәр әзерләү зарур.

## III. Программа чаралары

Программа чараларын финанслау республика бюджеты һәм бюджеттан тыш чыганаклар хисабыннан тормышка ашырыла. Программа чаралары комплексы капиталь кертемнәр һәм Программа юнәлешләре буенча башка ихтыяҗларга чыгымнар маддәсе буенча формалаша һәм финанслана.

Юл хәрәкәтендә балаларның имин катнашуын тәэмин итү буенча юнәлеш кысаларындагы эшчәнлек балаларны һәм үсмерләрне Юл хәрәкәте кагыйдәләренә

өйрәтүне, балаларда үзләрен юлларда имин хәрәкәт итү күнекмәләрен формалаштыруны, балаларның юл хәрәкәтендә катнашу дисциплинасын контрольдә тотуны һәм балаларның юл хәрәкәтендә имин катнашуы өчен шартлар тудыруны ныгытуны күздә тота.

Транспорт чараларының һәм җәяүлеләрнең хәрәкәтен оештыру системасын үстерү,юл шартлары иминлеген күтәрү буенча юнәлеш кысаларындагы эшчәнлек җәяүлеләрнең юл хәрәкәтендә куркынычсыз катнашуын, юл хәрәкәтендә куркыныч участоклар, бөкеләр һәм тыгылып торулар килеп чыгуны бетерү һәм профилактикалауны, куркынычсыз һәм нәтиҗәле график тәэмин итү максатыннан транспортны планлаштыруны оештыруны, интеллектуаль транспорт системасын үстерүне, юлларның пассив һәм авариядән соң куркынычсызлыгын һәмюл инфратсруктурасын тәэмин итүне күздә тота.

Юл-транспорт фаҗигаләрендә зыян күрүчеләргә ярдәм күрсәтү системасын үстерү буенча юнәлешләр кысаларындагы эшчәнлек юл-транспорт фаҗигаләрендә зыян күрүчеләргә медицина ярдәмен күрсәтүнең оперативлыгын һәм сыйфатын тәэмин итүне, медицина учреждениеләренә территориаль керү мөмкинлеген тәэмин итүне, юл-транспорт фаҗигаләрендә зыян күрүчеләргә ярдәм итүдә катнашучы хезмәтләренң координация дәрәҗәсен күтәрү; юл-транспорт фаҗигаләрендә зыян күрүчеләргә беренче ярдәм күрсәтү өлкәсендә яңа технологияләр кертүне күздә тота.

## IV. Программаны ресурслы тәэмин итү

Программаны ресурслы тәэмин итүне планлаштырганда җирле дәрәҗәдәге финанс-бюджет сферасында реаль ситуация, авария торышы, юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итү проблемасының югары икътисадый һәм социаль-демографик мөһимлеге, шулай ук регион ярдәме белән аны чынлыкта хәл итү мөмкинлеге исәпкә алынган.

Җәлеп ителгән җирле бюджет чараларның төп өлешен төзелеш, белем бирү учреждениеләре һәм сәламәтлек саклау учреждениеләре янәшәсендәге юлларда ясалма тигезсез урыннар кору, юлларның куркыныч участокларында юл билгеләре куюны да кертеп, капиталь кертемнәргә юнәлтү күздә тотыла.

Башка чыгымнарга бюджет чаралары балалар белем бирү учреждениеләрен фәнни-методик һәм мәгълүмти материаллар белән тәэмин итүгә, юл хәрәкәте иминлеге буенча өйрәтү семинарлары уздыруга, юл хәрәкәте иминлеге проблемаларына багышланган басма һәм видеопродукция булдыруга, яктылык кайтаргыч элементлар сатып алуга һәм белем бирү учреждениеләренә йөрүче балалар һәм үсмерләр арасында таратуга юнәлтеләчәк.

Бюджеттан тыш чыганакларны җәлеп итү Программаның түбәндәге юнәлешләре буенча чараларны тормышка ашыру өчен мөмкин:

юл хәрәкәтендә катнашучыларның үз-үзләрен куркыныч тотуын кисәтү системасын үстерү;

юл хәрәкәтендә балаларның куркынычсыз катнашуын тәэмин итү;

транспорт чаралары һәм җәяүлеләр хәрәкәтен оештыру, юл шартлары иминлеген күтәрү системасын үстерү.

Бюджеттан тыш чыганакларның чараларын җәлеп итү оешмаларның Программа чараларын финанслауга үз теләге белән алыну принцибына нигезләнгән.

Юл-транспорт фаҗигаләренең саны кимүдән аралаштырылган эффект алу мөмкинлеге оешмаларның әлеге чараларны финанслауга кызыксыну уянуында чагыла.

Кушымта № 1
“2019 елга Татарстан Республикасы
Минзәлә муниципаль районында
юл хәрәкәте иминлеген
күтәрү” максатчан программасына

# Программалы максатчан ысул булган шартларда авариялелекнең көтелгән күрсәткечләре

| | **2018 год** | | | **2019 год** | **2020 год** |
|---|---|---|---|---|---|
| | **план** | **факт** | **отклонение** | | |
| **Юл-транспорт фаҗигаләре нәтиҗәсендә һәлак булган затлар саны** | 11 | 9 | -3 (-25%) | 11 | 10 |
| **Зыяе күрүчеләр белән юл-транспорт фаҗигаләре саны** | 53 | 50 | -4 (-7,04%) | 53 | 52 |

Кушымта № 2
“2019 елга Татарстан Республикасы
Минзәлә муниципаль районында
юл хәрәкәте иминлеген
күтәрү” максатчан программасына

# Муниципаль максатчан Программа күрсәткечләренең көтелгән ирешү динамикасы

| **Күрсәткечләр** | |
|---|---|
| **Юл-транспорт фаҗигаләре нәтиҗәсендә һәлак булучы затларның потенциаль санын киметү (2012 ел белән чагыштырганда), кеше.** | |

Кушымта № 3
“2019 елга Татарстан Республикасы
Минзәлә муниципаль районында
юл хәрәкәте иминлеген
күтәрү” максатчан программасына

## Юл хәрәкәтендә катнашучыларга үз-үзләрен куркыныч тотуларын кисәтү һәм хокукый аңын күтәрүгә юнәлтелгән чаралар

(мең сум, тиешле елларга бәяләр фаразын исәпкә алып)

| тәртип № | Чаралар | Башкару срогы | Барлык финанслау күләме | Шул исәптән | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | Татарстан Республикасы бюджет чаралары хисабыннан | Муниципаль берәмлек чаралары хисабыннан | Бюдже тыш чыгана хисабы |
| Башка ихтыяҗлар | | | | | | |
| 1 | “Игътибар – балалар!”, “Игътибар – җәүяле!” “Итагатьле машина йөртүче”, “Зебра” һ.б. акцияләр уздыру<br>Юл хәрәкәтендә катнашучыларның дисциплинасын ныгытуга юнәлтелгән профилактик акцияләрне уздыруга мәгълүмати һәм реклама агентлыкларын җәлеп итү, юл хәрәкәте мәсьәләләре буенча материалларны массакүләм мәгълүмат чараларында урнаштыру; | 2019 | 15,00 | - | - | 15 |
| 2 | Төрле яшь категорияләрендә юл хәрәкәтендә катнашучыларның үз-үзләрен тоту культурасын пропагандалау буенча тематик телетапшырулар булдыру; | 2019 | 129,0 | 99,0 | - | 30 |
| 3 | Мәктәпкәчә яшьтәге балалар һәм мәктәп яшендәге укучылар арасында яктылык кайтаручы җайланмаларны әзерләү һәм тарату; | 2019 | 40,0 | - | 40,0 | - |
| 4 | Мәктәпкәчә яшьтәге һәм мәктәптә укучы балалар белән квартал саен юл хәрәкәте иминлеге буенча дәресләр уздыру | 2019 | 7 | - | - | 7, |
| | БАРЛЫГЫ | | 191,0 | 99,0 | 40,0 | 52 |

Кушымта № 4
“2019 елга Татарстан Республикасы
Минзәлә муниципаль районында
юл хәрәкәте иминлеген
күтәрү” максатчан программасына

# Шәһәрләрдә транспорт һәм җәяүлеләр хәрәкәтен оештыруны камилләштерүгә юнәлтелгән оештыру-планлаштыру һәм инженерлык чаралары

(мең сум, тиешле елларга бәяләр фаразын исәпкә алып)

| Тәртип № | Чаралар | Башкару срогы | Барлык финанслау күләме | Шул исәптән | | | Башкару өчен |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | Татарстан Республикасы Бюджет чаралары хисабыннан | Муниципаль берәмлек чаралары хисабыннан | Бюджеттан тыш чыганаклар чаралары хисабыннан | |
| Капиталь кертемнәр | | | | | | | |
| 1 | Гомуми кулланылыштагы юлларны ясалма яктырту (шул исәптән, юл-транспорт концентрациясе урыннарында) | 2019 | 4300,0 | 3300,0 | 1000,0 | - | Минзәлә муниц район башкарма комитетының “Урамнарны як торгызу” “Главинвестстр программасы бу |
| 3 | Кышкы чорда Минзәлә муниципаль районының урам-юл челтәрен агымдагы тәртиптә тоту | 2019 | 13 000 | - | 13 000 | - | Минзәлә шәһәр башкарма коми |
| 5 | Юл билгеләрен кую һәм алыштыру | 2019 | 200,0 | - | 200,0 | - | Минзәлә шәһәр башкарма коми |
| 6 | Булган асфальт катламының чокырларын ремонтлауны уздыру | 2019 | 1800,0 | - | 1800,0 | - | |
| 7 | Юл-урам разметкаларын кую | 2019 | 290,0 | - | 290,0 | - | |
| 9 | Программа кысаларында урам юлларын норматив хәлгә китерү | 2019 | 19 800,0 | - | 19 800,0 | - | 2018 елга Татар Республикасы М муниципаль рай җирле әһәмиятк булган гомуми |

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | | кулланудагы юл<br>юл эшләрен баш<br>программасы<br>кысаларында (Ю<br>фонды) |
| | Минзәлә шәһәрендә ишегалды территорияләрен һәм квартал эчендәге керү-чыгу юлларын ремонтлау | 2019 | 35 000 | 35 000 | | | Минзәлә шәһәр<br>башкарма коми |
| | Минзәлә шәһәрендә тротуарлар урнаштыру | 2019 | 4 500 | | | 4 500 | Минзәлә шәһәр<br>башкарма коми |
| | “Минзәлә район үзәк хастаханәсе” Дәүләт автоном учреждениесендә стоянка урнаштыру | 2019 | 2 000 | | | 2 000 | Минзәлә шәһәр<br>башкарма коми |
| | **БАРЛЫГЫ** | | **80 890** | **38 300** | **36 090** | **6 500** | |

Кушымта № 5
“2019 елга Татарстан Республикасы
Минзәлә муниципаль районында
юл хәрәкәте иминлеген
күтәрү” максатчан программасына

## Республика һәм җирле бюджет чаралары һәм юнәлешләр буенча, башка чыганаклар буенча “2018 елга Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль берәмлегендә юл хәрәкәте куркынычсызлыгын күтәрү” максатчан программасын финанслау күләме

(мең сум, тиешле елларга бәяләр фаразын исәпкә алып)

| | 2018 елда (программа чаралары на юнәлтелгән чаралар) барлыгы | Татарстан Республикасы бюджет чаралары | | | Җирле бюджет чаралары | | | Бюджеттан тыш чыганаклар |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | НИОКР | Капитальль кертемнәр | Башка ихтыяҗлар | НИОКР | Капитальль кертемнәр | Башка ихтыяҗлар | Капиталь кертемнәр |
| Юл хәрәкәтендә катнашучыларның үз-үзләрен куркыныч тотуын кисәтү һәм хокукый үзаңын күтәрү | 191 | 0 | 0 | 99 | 0 | 0 | 92 | |
| Шәһәрләрдә транспортның һәм җәяүлеләрнең хәрәкәтен оештыруны камилләштерүгә юнәлтелгән оештыру-планлаштыру һәм инженерлык чаралары | 80 890 | 0 | 38 300 | 0 | | 36 090 | 0 | 6 500 |
| Барлыгы: | 81 081 | 0 | 41 600 | 99 | 0 | 36 090 | 92 | 6 500 |